1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

# Шәһри КАЗАН

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ 16+

ШК № 27 (7011) | ЧӘРШӘМБЕ | 15 апрель | 2026 ел

2026
ГОД ВОИНСКОЙ И ТРУДОВОЙ ДОБЛЕСТИ
ХӘРБИ БАТЫРЛЫК ҺӘМ ХЕЗМӘТ ФИДАКАРЬЛЕГЕ ЕЛЫ

## Декадада газетага язылу бәяләре

6 – 16 апрель

П2395 язылу индексы — комплект, чәршәмбе-җомга — 1369,56 сум (гадәти бәя 1569,24 сум)

П2430 язылу индексы — чәршәмбе саны — 732,78 сум (гадәти бәя 839,94 сум)

ПК313 язылу индексы — җомга саны, «Шәһри Казан. Язмыш» — 699,06 сум (гадәти бәя 797,88 сум)



ФОТО: TATAR-INFORM.RU

# Дөрес яшибезме икән соң?..

**Узган елларда вакыт машинасына утырып, үткәннәргә сәяхәт иткән төсле булдык. Казан театрлары сәхнәсенә халык яраткан классик әсәрләр кайтты: Камал театрында өч дистә ел аншлаг белән барган – Туфан Миңнуллин әсәре буенча – «Әлдермештән Әлмәндәр», ә Тинчурин театрында Шәриф Хөсәенов әсәре буенча «Әни килде» спектакле.**

Бу әсәрләрнең янә сәхнәгә кайтуы сөендерә, әлбәттә. Мәгънәле әсәрләр сандыкта җиде кат йозак астында тузан җыеп ятарга тиеш түгел. Куйсыннар, күреп, белеп торыйк. «Театр яктылыкка, нурга илтә», – диләр бит. «Әлдермештән Әлмәндәр» – җирдә яшәүгә, күңел хөрлегенә дан җырласа, «Әни килде» – гомер көзенә җитеп үз балаларына сыймаган ана трагедиясен ача. Ике спектакль дә мәңгелек темаларны, проблемаларны күтәрә. Андый әсәрләрнең сәхнәгә кайтуы: Әлмәндәр карт кебек яшәгән һәр көннән ямь-тәм табып яши белмәүне, балаларның тәрбияләп үстергән газиз анага рәхмәтле була алмавын искәртә.

Яшәү беркайчан җиңел булмаган. Аеруча Әлмәндәр карт яшәгән XX гасыр гына ни тора. Рус-япон сугышы, Гражданнар сугышы, Бөек Ватан сугышы... Әмма бу әсәрләрнең геройлары елар вакытта да сөенерлек сәбәп таба белгән.

Хәзер тормыш җитеш, йортларыбыз җылы, тамак тук. Әниләрне өй түрендә кунак итә торган, Әлмәндәр карт кебек сөенеп яши торган заман. Әмма картлар йортларында балалары булып та соңгы көннәрен яшәүче картлар, чебеннән фил ясап уфтанып йөрүче кешеләр арткан-нан-арта бара. «Михнәткә түзеп була, рәхәткә чыдап кара», – дип юкка әйтмәгәннәр.

Театрларда премьералар уйналадыра. Шул ук вакытта тагын бер кызганыч якны да ачып бирә. Соңгы дистә елда тарихка кереп калырлык, еллар дәвамында сәхнәләрдә уйналырлык әсәрләр бармы? Искә төшерү кыен. Димәк, безнең чорны сурәтләрлек әсәрләр юк. Дөрес яшибезме икән соң?

**Илгизә Галиуллина.**

